РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
СОВЕТ КИЯТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫЯТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**КАРАР**
**РЕШЕНИЕ**

30 май 2015 ел N 1-67

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Кыят авыл җирлеге советының "физик затлар
милкенә салым турында" 2014 елның 14 ноябрендәге
1-55 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кыят авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге Советының "Физик затлар милкенә салым турында" 2014елның 14 ноябрендәге 1-55 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

а) 1 пунктчада:

яңа абзац белән түбәндәге эчтәлектәге өченче абзацны тулыландырырга:

"мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннар. Ставка салым түләүче сайлаган бер гаражга яки машина-урынга карата билгеләнә";

Өченче абзацны дүртенче дип санарга;

б) пунктчада:

икенче һәм өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

"6) 2015 елда- 1,5 процент, 2016елда-1,8 процент, 2017 елда – 2 процент һәм киләсе елларда түбәндәге нисбәттә:

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары";

1.2. Түбәндәге эчтәлекле яңа 3 пунктны өстәргә:

"3. Ике фатирлы күпфатирлы бер катлы торак йортта фатирга милек хокукына ия булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метры кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнгән суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәрберсе өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташлама суммасы уртак милектә катнашучыларның һәрберсе өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пунктка ярашлы исәпләнгән ташлама суммасы исәпләнгән салым суммасыннан аның исәбеннән башка артмаска тиеш.";

1.3. 3, 4 һәм 5 пунктларын 4, 5 һәм 6 пунктлар дип санарга .

2. Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә үз көчен җәелдерә һәм җирлекнең махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларында һәм Буа муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

Буа муниципаль районы Кыят
авыл җирлеге башлыгы М.М. Храмова